**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 11 сентябрендәге 3854 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2020 елның 8 апрелендәге 1041 номерлы**
**«2020-2024 елларга Казан шәһәрендә энергияне**
**сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру**
**муниципаль программасын раслау турында»гы**
**карарына үзгәрешләр кертү хакында**

2020-2024 елларга Казан шәһәрендә энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру муниципаль программасын (алга таба – Программа) актуальләштерү һәм Программаны 2026 елга кадәр озайту максатыннан **карар бирәм:**

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2020 елның 8 апрелендәге 1041 номерлы «2020-2024 елларга Казан шәһәрендә энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру Программасын раслау турында»гы карарына (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2021 елның 21 маендагы 1267 номерлы, 2022 елның 10 октябрендәге 3450 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. карар атамасындагы, 1 пункттагы «2020-2024 елларга» сүзләрен «2020-2026 елларга» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. карар кушымтасының:

1.2.1. атамасындагы «2020-2024 елларга» сүзләрен «2020-2026 елларга» сүзләренә алмаштырырга;

1.2.2. «2020-2024 елларга Казан шәһәрендә энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру муниципаль программасының паспорты» I бүлегендә:

1.2.2.1. «Программаның исеме», «Программаны гамәлгә ашыру сроклары һәм этаплары» юлларындагы «2020-2024 елларга» сүзләрен «2020-2026 елларга» сүзләренә алмаштырырга;

1.2.2.2 «Программаның максатларын һәм бурычларын гамәлгә ашыруның елларга бүленгән көтелгән соңгы нәтиҗәләре (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм Программаның нәтиҗәлелеге күрсәткечләре» юлындагы энергетика ресурсларын чагыштырып куллануны яңа редакциядә бирергә:

| «Ресурс | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел | 2026 ел |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Электр энергиясе, 1 кешегә кВт/сәг. | 101,9 | 116,0 | 116,16 | 117,4 | 117,6 | 117,8 | 117,8 |
| Җылылык энергиясе, 1 кешегә Гкал. | 0,15 | 0,16 | 0,15 | 0,12 | 0,12 | 0,13 | 0,13 |
| Салкын су, 1 кешегә куб.м | 1,15 | 1,40 | 1,28 | 1,32 | 1,32 | 1,35 | 1,35» |

1.3. «Программаның төп максатлары, бурычлары, чаралары. Ахыргы нәтиҗәләрне, срокларны һәм тормышка ашыру этапларын тасвирлау» III бүлегендә «Муниципаль бюджет учреждениеләре тарафыннан энергетика ресурсларын чагыштырмача куллану» таблицасын яңа редакциядә бирергә:

| Күрсәткечнең исеме | Факт | | | | Фараз | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел | 2026 ел |
| Электр энергиясе, 1 кешегә кВт/сәг. | 101,9 | 116,0 | 116,16 | 117,4 | 117,6 | 117,8 | 117,8 |
| Җылылык энергиясе, 1 кешегә Гкал. | 0,15 | 0,16 | 0,15 | 0,12 | 0,12 | 0,13 | 0,13 |
| Салкын су, 1 кешегә куб.м | 1,15 | 1,40 | 1,28 | 1,32 | 1,32 | 1,35 | 1,35» |

1.4. Программаның 1 номерлы кушымтасындагы реквизитларда «2020-2024 елларга» сүзләрен «2020-2026 елларга» сүзләренә алмаштырырга;

1.5. Программаның 1 номерлы кушымтасын әлеге карарның кушымтасына нигезләнгән редакциядә бирергә.

1.6. Программаның 2 номерлы кушымтасындагы реквизитларда «2020-2024 елларга» сүзләрен «2020-2026 елларга» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга һәм Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан

Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.С.Шакировка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 11 сентябрендәге 3854 номерлы карарына кушымта

## Программаның максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм Программа чараларын финанслау

| Максатның атамасы | Бурычның атамасы | Төп чараларның исемнәре | Башкаручылар | Төп чараларны гамәлгә ашыру сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикатор күрсәткечләре | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | 2019 ел (база елы) | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел | 2026 ел |
| Казан шәһәрендә энергияне сак тотуга һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыруга юнәлдерелгән энергия ресурсларын куллануның нәтиҗәле системасын формалаштыру | 1. Энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру өлкәсендәге проектларны һәм чараларны гамәлгә ашыру өчен уңайлы шартлар тудыру | 1. Урам яктыртуны модернизацияләүгә юнәлдерелгән энергия сервисы контрактын төзү | Казан шәһәре Башкарма комитетының Тышкы төзекләндерү комитеты | 2020-2026 еллар | Энергия сервисы буенча төзелгән килешүләр (контрактлар) саны | - | 1 | - | - | - | 1 | - | - |

| Максатның атамасы | Бурычның атамасы | Төп чараларның исемнәре | Башкаручылар | Төп чараларны гамәлгә ашыру сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикатор күрсәткечләре | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | 2019 ел (база елы) | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел | 2026 ел |
| | | 2. Юлларда һәм урамнарда энергия ягыннан нәтиҗәле яктырту дәрәҗәсен арттыру | Казан шәһәре Башкарма комитетының Тышкы төзекләндерү комитеты | 2020-2026 еллар | Урам яктырту системаларында энергияне аз кулланучы диодлы яктырткычларның өлеше (%) | 20 | 36 | 41 | 44 | 52,3 | 56 | 59 | 62 |
| | | 3. Казан шәһәренең муниципаль бюджет, казна һәм автоном учреждениеләре тарафыннан энергия сервисы контрактларын төзү | Казан шәһәре Башкарма комитетының структур бүлекчәләре, муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләр | 2020-2026 еллар | Энергия сервисы буенча төзелгән килешүләр (контрактлар) саны | 2 | 1 | - | - | - | - | - | - |
| | | 4. Энергия декларацияләрен тутыру | Муниципаль учреждениеләр | 2020-2026 еллар | Учреждениеләрнең гомуми санынннан энергия декларациясен тутырган учреждениеләр өлеше | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 |

| **Максатның атамасы** | **Бурычның атамасы** | **Төп чараларның исемнәре** | **Башкаручылар** | **Төп чараларны гамәлгә ашыру сроклары** | **Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре** | **Индикатор күрсәткечләре** | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | **2019 ел (база елы)** | **2020 ел** | **2021 ел** | **2022 ел** | **2023 ел** | **2024 ел** | **2025 ел** | **2026 ел** |
| | | 5. Торак секторда энергия нәтиҗәлелеге чараларын гамәлгә кертү | Казан шәһәре Башкарма комитетының Торак-коммуналь хуҗалык комитеты | 2020-2026 еллар | Күпфатирлы йортларның гомуми санынннан энергия ресурслары төрләре буенча: | | | | | | | | |
| | | | | | җылылык энергиясе, | 67,2 | 67,2 | 67,2 | 68,0 | 68,4 | 70 | 75 | 80 |
| | | | | | электр энергиясе, | 74,1 | 74,1 | 74,1 | 75,0 | 75,3 | 80 | 85 | 90 |
| | | | | | кайнар су белән тәэмин итү | 29,4 | 29,4 | 29,4 | 30,0 | 30,4 | 50 | 60 | 70 |
| | | | | | салкын су белән тәэмин итү буенча энергетика ресурсларын исәпкә алучы коллектив (гомумйорт) приборлары белән җиһазландырылган күпфатирлы йортлар өлеше (%) | 67,6 | 67,6 | 67,6 | 68,0 | 68,9 | 70 | 75 | 80 |

| **Максатның атамасы** | **Бурычның атамасы** | **Төп чараларның исемнәре** | **Башкаручылар** | **Төп чараларны гамәлгә ашыру срокларлары** | **Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре** | **Индикатор күрсәткечләре** | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | **2019 ел (база елы)** | **2020 ел** | **2021 ел** | **2022 ел** | **2023 ел** | **2024 ел** | **2025 ел** | **2026 ел** |
| | | 6. Гамәлдәге муниципаль, инвестиция программалары кысаларында энергияне сак тоту чараларын гамәлгә ашыру | Казан шәһәре Башкарма комитетының структур бүлекчәләре, муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләр, предприятиеләр | 2020-2026 еллар | Энергия саклау чараларын гамәлгә ашыру турында мәгълүмат бирү Программаның 2 номерлы кушымтасы нигезендә төзелә (әйе/юк) | юк | әйе | әйе | әйе | әйе | әйе | әйе | әйе |
| | 2. Энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру чараларын мәгълүмати тәэмин итүне үстерү, энергияне нәтиҗәле куллана торган яшәү рәвешен пропагандалау | 1. Энергетика ресурсларыннан нәтиҗәле файдалануны пропагандалаучы чаралар (мәгариф учреждениеләрендә дәресләр, мәдәни-массакүләм чаралар) үткәрү | Казан шәһәре Башкарма комитетының структур бүлекчәләре | 2020-2026 еллар | Энергетика ресурсларыннан нәтиҗәле файдалану мәсьәләләре буенча дәресләр, чаралар саны | 4 | 314 | 322 | 326 | 326 | 350 | 350 | 350 |
| | | 2. Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталына урнаштырылган | Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының икътисади үсеш | 2020-2026 еллар | Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында | 10 | 23 | 24 | 24 | 25 | 24 | 24 | 24 |

| Максатның атамасы | Бурычның атамасы | Төп чараларның исемнәре | Башкаручылар | Төп чараларны гамәлгә ашыру сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикатор күрсәткечләре | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | 2019 ел (база елы) | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел | 2026 ел |
| | | ресурслардан нәтиҗәле файдалануы турындагы язмалар саны | комитеты, Казан шәһәре иҗтимагый үзәге, Казан шәһәре Башкарма комитетының структур бүлекчәләре | | ресурслардан нәтиҗәле файдалану мәсьәләләре буенча урнаштырылган язмалар саны | | | | | | | | |
| | 3. Автомобиль транспорты паркының матди-техник базасын автотранспорт чараларының газмотор ягулыгы буларак компримациялән гән табигый газдан өстенлекле файдалануы хисабына яңарту | 1. Газ-мотор ягулыгында эшләүче автотранспорт чараларын сатып алу | Казан шәһәре Башкарма комитетының Транспорт комитеты, муниципаль транспорт предприятиеләре | 2020-2026 еллар | Газ-мотор ягулыгында эшләүче сатып алынган автотранспорт чаралары саны | 104 | 73 | 40 | - | - | 157 | 120 | - |
| | | 2. Бюджет учреждениеләре нең автотранспорт чараларын газ-мотор ягулыгына күчерү | Хуҗалык-транспорт идарәсе | 2020-2026 еллар | Газ-мотор ягулыгыннан файдалана торган автомобильләр саны | - | 31 | - | 24 | 8 | 28 | - | - |